*Мөслим гимназиясенең 7 нче б сыйныфы укучыларының*
*«ЖУРАТЕГА» проекты кысаларындагы газетасы*

7Б Жу Ра Те Га

# ТЫЛСЫМ+

№3 (35)

Гыйнвар, 2020 нче ел

## Бу санда

*Хәтер чемоданы* 2

*Мин кышны ни өчен яратам?* 3

*Бу - без!* 4

*Мизгел! Тукта!* 4

## СЫЙНЫФ СУЛЫШЫ

### Тату сыйныф сере нәрсәдә?




Без, 7 нче б сыйныфы укучылары һәм ата-аналар комитеты, “Тату сыйныф серләре” конкурсында районкүләм һәм зона ярышларында 2 нче урынны яуладык, республика этабына үттек.

Безнең тату команда “визит карточкасы” һәм проектлар тәкъдим итте. Сыйныфның эшчәнлеге белән махсус күргәзмәдә дә танышырга мөмкин иде.

23 укучы, ата-ана һәм сыйныф җитәкчесенең бер юнәлештә эшләве, теләктәшлек, хезмәттәшлек нәтиҗәсе бу!





### Спорт яңалыклары




Сыйныфташыбыз Динар Хафизовны чираттагы уңышы белән котлыйбыз! Илһам Авзалов истәлегенә багышланган 2004 елгы һәм яшьрәк егет-кызлар арасында оештырылган районара билбау көрәшендә үз авырлыгында өченче урын яулады.

Балтач районында уздырылган кул көрәше буенча республика ярышында сыйныфташларыбыз катнашты. Каюмов Әмир беренче, Бариева Илина өченче урынга лаек булды.

*Уңышларыгыз дәвамлы булсын, Динар, Илина, Әмир!*

# БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 75 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН СӘХИФӘ

***Районыбызда ТАССР ның 100 еллыгына багышланган чараларга старт бирелде.***

***2020 елда Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгы билгеләп үтеләчәк. Русия Президенты Владимир Путин указы белән ул "Хәтер һәм дан елы" дип игълан ителде.***

***Гимназиядә оештырылган барлык чараларда ТАССР ның 100 еллыгы, Бөек Җиңүнең 75 еллыгы темасы чагылыш таба.***

## ХӘТЕР ЧЕМОДАНЫ

***”Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк”, диләр. Борынгы тамырларыбызны, үз нәселебез тарихын белмәсәк, бүгенге яшәешебезнең кадере булырмы? Киләчәктә безне ни көтәр?***

### *Фамилиябезнең килеп чыгышын ачыклыйбыз*

Һәр гаилә, минемчә, зур агачка охшаган. Тамырлары белән ул түбәнгә, безнең борынгы бабаларыбыз яшәгән дәверләргә барып тоташа, ә ботаклары һәм яфраклары – без үзебез.

Безнең гаиләбез артык зур түгел. Мин әниемне һәм энемне бик яратам. Әниемнең кыз фамилиясе Гайсина булган. Әниемнең әтисе, ягъни бабам да Гайсин фамилиясен йөртә. Ул Әмәкәй авылында яши, гомере буе механизатор булып эшләде. Хезмәт яратуы, кешелекле булганы өчен бабамны бик хөрмәт итәләр.


Минем әле картбабам да исән. Аңа 94 яшь. Миркасим бабабыз безнең әбиебез белән бабабыз тәрбиясендә яши. Ул сугыш елларына туры килгән яшьлеге турында бик еш искә ала. Ачлык, ялангачлык, хәерчелек, авыр хезмәт белән үткән аның балалык һәм үсмер еллары. Хезмәт көне хисабына эшләүләр, аңа тигән санаулы граммнар турында сөйләгәндә, бабамның күзләре яшьләнә. Барлык ир-ат фронтта булганга, яшүсмер бала килеш, аңа бригадир йөгән тартырга туры килә. Тумыштан бер күзе сукыр булганга күрә, аны фронтка алмыйлар. Шулай булса да, карт бабабыз Җиңү көнен якынайту өчен тылда тырыш хезмәт куя. Гайсиннар нәселеннән Миркасим бабамның 3 абыйсы сугышка киткән. Алар өчесе дә кире кайтмаган. Бабам аларны бик еш искә ала. Тормышның рәхәтен күрмичә, ять-яшь килеш яу кырында ятып калдылар, каберләре дә билгеле түгел ичмасам, дип өзгәләнә.

Картбабайның әтисе Нәбиулла исемле була. Ул бик шәп балта остасы булган. Авылда бөтен кешенең йорты аның алтын куллары белән эшләнгән. Аның атасы Гайсә исемле булган. Менә шул буыннан бирле минем әниемнең нәселендә Гайсин фамилиясен йөртәләр. Гайсә – Пәйгамбәр исеме. Ул “Аллаһның рәхмәте, шәфкате” дигәнне аңлата. Бу фамилия нәселне саклап тора кебек тоела мина.

Әбием белән бабам янында мин каникулларны уздырам. Алар мине бик яраталар, үзләренең нәсел дәвамчылары итеп күрәләр, киләчәккә зур өметләр баглыйлар. Шулай булмыйни! Мин бит аларның тәүге оныклары! Мин дә, үз чиратымда, Гайсиннарның матур традицияләрен дәвам итәрмен дип уйлыйм.

***Ранис Хәертдинов***

## *Мин – хәрбиләр гаиләсеннән*



Хәрби кеше - батырлык һәм кыюлык өлгесе. Хәрбиләргә җаваплылык хисе хас, чөнки ил язмышы, халык язмышы аларның үзләре башкарган эшләренә намуслы карашына, ил алдындагы бурычларын ничек үтәвенә дә бәйле.

Мин хәрбиләр гаиләсендә тәрбияләнеп үстем. Тирә-ягымдагы кешеләрнең ярдәмгә ашкынып торуы, принципиаль булуы, һәрвакыт җитди булулары - минем өчен норма. Мондый атмосфера бары тик хәрбиләр гаиләсендә генә була торгандыр.

Гаиләбезнең терәге – әтием Вильданов Шакирҗан Салих улы. Ул Мөслим районы Каенсаз авылында туган,1984 нче елда Совет Армиясе сафларына чакырылган. Самара шәһәрендә укыган, аннары Венгриядә хезмәт иткән. Ике ел хәрби хезмәттән соң Мәскәүдә прапорщиклар мәктәбендә укыган һәм Ерак Көнчыгышка юллама алган. Приморск өлкәсендә 2001 нче елга кадәр хезмәт иткән. Әтием радиоразведка гаскәрләрендә хезмәт итә, рота командиры була. Солдатларны хәрби техникага, корал белән эш итәргә өйрәтә. Ул үзе дә дисциплина ярата, спорт белән шөгыльләнә, башкалардан да шуны таләп итә. Бу сыйфаты аның хәзер дә саклана: ул һәрвакыт җыйнак, төгәл, пөхтә йөри.


Әтием 25 елдан соң хәрби хезмәтен 2011 нче елда Самара өлкәсендә тәгәлләде.

Минем әти кебек әтиләр башкаларның төшенә дә кермидер. Ул хезмәтендә үз эшен төгәл итеп башкаруы белән ихтирамга лаек булса, гаиләбездә исә – безне бөтенебезне бердәй яратучы әти. Әти безне - өч малайны үз үрнәгендә тәрбияләде. Без аның хезмәт сөючәнлегенә, кешелеклелегенә, оешкан булуына, үз сүзендә тора белүенә, төгәллегенә сокланабыз, һәр яктан аңа ошарга тырышабыз.

Безнең әниебез Вильданова Зөлфия дә 22 ел стажлы хәрби кеше. Приморск өлкәсендә 9 ел хезмәт иткәннән соң, Мөслим эчке эшләр бүлегендә эшләде. Безнең гаиләдә алган тәрбиябез киләчәктә үз тормышыбызны корганда кирәк булыр дип уйлыйм. Мин үземнең әти-әниемә рәхмәтле.

***Шамил Вильданов***

# МИН КЫШНЫ НИ ӨЧЕН ЯРАТАМ?



**Гүзәл Гыйзетдинов:**
Быелгы кышны ничек көткәнемне белсәгез иде сез! Минем кебек беренче карны көтеп алучы булды микән?! Беренче яуган кар бер генә тәүлек торды да эреп суга әйләнде. Сеңлем белән ясап куйган Кар Бабай, иртән торуга, башындагы чиләген бер, борынына куйган кишерен икенче якка тәгәрәтеп, күл хасил итеп җәелгән иде...

**Динар Фазлыев:**
Минем өчен иң рәхәте – Кыш Бабай бүләген ачу. Акылым белән Кыш бабай булуына ышанмасам да, нишләптер шул бүләкне һаман көтәм. Әти-әниләр дә һаман безне кызыктырып, ел саен саллы бүләкләр әзерлиләр. Тимераяк, чаңгы бар, телефон булды, быел нинди сюрприз көтә икән?..

**Ильвина Хәмидуллина:**
Кышкы озын кичләрдә без үзебезнең Мөслимдә дә шуар өчен рәхәт урыннар табабыз. Иске Авыл тавы, Имәнәй тавында, карьерда тау шуу искиткеч рәхәт. Биек таудан җилдәй очып төшәсең, күзләргә кар тула, битләр кызышып яна башлый. Шулай булса да, беркем дә кайтырга ашыкмый. “Соңгы тапкыр шуабыз”, - дип, үз-үзебезне алдап, ничә тапкыр шуып төшәбез микән?! Шуннан да рәхәт уен юктыр.

**Абдуллин Эмиль:**
Мин кышны салкыннары, саф һавасы, күзләрне чагылдырып ялтыраган ап-ак карлары өчен яратам. Минем яраткан спорт шөгылем дә кыш белән бәйле. Кар яуганчы ук тимераякларымны әзерләп куям. Боз гына кирәк. Мәктәп янында шугалак катырганны түземсезлек белән көтеп алабыз. Кар күп яуса, карны көрибез. Кыш көне сыйныфташлар белән тау шуарга бару, чаңгыда йөрү өчен рәхәт.
Җепшек көннәрдә кар тәгәрәтеп сыннар ясыйбыз. Кышның бөтен рәхәте шунда! Безнең гаиләдә өч кешенең туган көннәре кыш айларына туры килә. Минем туган көнем дә кыш көне.

**Илина Бариева:**
Кышкы матурлык күңелләрне, күзне иркәли. Керфекләргә, чәчләргә күбәләк карлар килеп куна. Качып кына бер уч карны бияләй башына элеп аласың да, беркем күрмәгәндә ялт итеп ашап куясың... Әәәх, могҗиза... Яратам да шул ап-ак карны. Аптырыйм: өлкәннәр шуны аңламый. Янәсе, тамагың авыртыр...
Тагын ни өчен кышны яратам, дисезме? Коры суыкларда калын итеп киенеп, шыгырдаган кар өстеннән киез итекләр киеп йөрергә яратам мин. Шыгырт-шыгырт, шыгырт-шыгырт... Барасың да барасың... Рәхәт!

**Рәзилә Ахунова:**
Кем ничектер, мин беркем дә аяк басмаган тирән кар эчендә эз ясап йөрергә яратам. Үземне өр-яңа җирләр үзләштергәндәй хис итәм. Тун итәкләре бозланып, итек эчләренә кар тулып кайтып керәм. Итек табанына ябышкан карлы “үкчәләр”дә басып калып булмый, ишектән керү белән, таеп егылам. Мине “коткарырга” әти белән әни килеп җитәләр. И кызык та шул чакта. Мин көләм дә көләм, ә әни итекне салдыра алмый, чөнки ул тыгыз кар белән тулган. Әни ачуланган була, әти яклый: “Ярар, әнисе, ачуланма, шулай да уйнамагач, бала чактан нинди истәлек калсын,” - ди. Тирән итеп кар яуганны көтәм...

**Әмир Каюмов:**
Безнең гаилә – бик тату гаилә. Җәен дә, язын-көзен дә, кышын да әти-әниләр безгә төрле шөгыльләр табып кына тора. Бергәләп чаңгы шуабыз, шугалакка тимераякта йөрергә барабыз. Әти безне ял көннәрендә снегоходта йөртә. Без аның арбасына кереп утырабыз да тирән кар эченнән җәй көне җиләк җыйган болыннарга, көз көне гөмбә җыйган урман аланнарына барып чыгабыз. Һәр ел фасылының үз матурлыгы бар. Аны тоя белергә генә кирәк.



## Б У — Б Е З !



Дус һәм тату, матур, батыр
Тапкыр, зирәк, уңганнар.
7нче Бда укыйлар
Һәр яклап та булганнар.

Тәрбияле, зыялы да,
Шаян-шук та үзебез.
Ачу саклый белмәгәнгә
Гел елмая күзебез.

Сүзгә кермибез кесәгә,
Чатнап, горур торабыз.
Тәнәфестә җыелышып
Яңа планнар корабыз.

Дус сыйныфның сере гади -
Кадер.Хөрмәт. Ихтирам.
Шулкадәрле тату булгач...
Җиңәрбез дә, ихтимал.

***Лилия Шәймиева***

## М И З Г Е Л !  Т У К Т А !














**ТЫЛСЫМ+**

Гыйнвар, 2020 нче ел

***Мөслим гимназиясенең***
***7 нче б сыйныфы укучылары***
***газетасы***

**Баш мөхәррир:** Мөхәммәтҗанова Г.И.

**Мөхәррир:** Фәтхиева Алинә

**Корректор:** Асылгараева Анжела
**Корреспондентлар:** Вильданов Шамил
Садриева Рания
**Дизайнер:** Хәйретдинов Ранис
**Компьютерда җыючы:** Муллакаев Рамил

**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а

**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru

**Тираж**: 100